РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава
Микулинского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 74, Азнакаевский район,
с.АМикулино, 423306,
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге
башлыгы

Советская ур., 74 йорт, Азнакай районы,
Микулино авылы, 423306
тел./факс (885592)33-2-09
E-mail: Mikul.Azn@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

от «16»03.2023г. **№ 1**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының "Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең 2022 елгы бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын яклау максатыннан «2022 елда Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының ачык тыңлаулар уздыру юлы белән карар проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының "Микулино авыл җирлеге" муниципаль берәмлек уставының 20 статьясы нигезендә, ТР Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең 2012 елның 21 апрелендәге 42 нче карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә белән, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Советының «2022 елда Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә (1 нче кушымта).

2. Ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы булып Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге башлыгы тора.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты - 2023 елның 10 апрелендә 15.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны - Микулино авылы мәдәният йорты

- тикшерелгән мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча бирелә: 423306, ТР, Азнакай районы, Микулино авылы, Совет урамы, 74 йорт

4. Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге башкарма комитетына «2022 елда Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының гамәлдәге законнар, Микулино авыл җирлегенең норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

5. Әлеге карарны һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының « Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2022 елга бюджет үтәлеше турында» карар проектын, 2023 елның 16 мартыннан да соңга калмыйча, Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында " түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә. http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге башлыгы И.А. Такиуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МИКУЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН